Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы


# DARELFONYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№23 (116)

4 сентябрь 2014 ел






# Ышанычлы канат астында




Матбугат үзәге һәм Влад Михневский фотолары

Табигатьтә көз... Әле кайчан гына чыгарылыш кичәләрендә студентлар, туган уку йортларын калдырып, зур тормыш юлына аяк басты. 210 еллык тарихы булган Казан университеты һаман яшь кала бирә. Быел ул тагын үз канаты астына яңа гына мәктәп бусагасын атлап чыккан кичәге укучыларны кабул итте. Иң матур кеше – белемгә омтылган кеше. Белемдә – бәхет, белемсезгә – дөнья ләхет, ди бит татар халык мәкале дә. Шуңа күрә һәрчак белемле булыйк, белемгә омтылыйк!

## ● Вакыйгалар эзеннән

**2 СЕНТЯБРЬ** көнне КФУның фәнни-мәгариф кластеры составындагы Казан педагогика көллияте базасында педагогик хезмәткәрләр әзерләү буенча **РЕСУРСЛАР ҮЗӘГЕНЕҢ АЧЫЛЫШЫ БУЛДЫ**. Анда КФУ ректоры **И.ГАФУРОВ** белән берррәттән ТР Президенты **Р.МИҢНЕХАНОВ**, РФнең Мәгариф һәм фән министры урынбасары **А.ПОВАЛКО** катнашты. А.Повалко КФУга да визит ясады. Ул уку йортыбыз һәм аның эшчәнлеге белән танышты. Башта ул Фундаменталь медицина һәм биология институтын, аның Симуляцион медицина үзәген, соңрак Физика институтын, А.М.Бутлеров ис. химия институтын һәм Геология һәм кара алтын-газ технологияләр институтының яңа корпусларын карап чыкты.

• • • •

Шул ук көнне КФУ ректоры **И.ГАФУРОВ ГЕРМАНИЯ-РОССИЯ ЯҢА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ИНСТИТУТЫНЫҢ АЧЫЛЫШЫНДА КАТНАШТЫ**. Яңа уку йорты – инженерлар әзерли торган проект. Ул – А.Н.Туполев ис. Казан милли тикшеренү техник университетының яңа бүлекчәсе.

• • • •

**2 СЕНТЯБРЬДӘ** Алабуга институтының инженерия-технология һәм икътисад факультеты студентлары Алабуга автомобиль заводының генераль директоры **К.ГАЛИМОВ** белән **ОЧРАШТЫ**. Җитәкче ЕлАЗ эшчәнлегенең үзенчәлеге һәм перспективалары турында сөйләде. Җыелыш азагында студентлар үзләрен кызыксындырган барлык сорауларга җавап алды.

• • • •

Җәйнең соңгы көннәрендә Геология һәм кара алтын-газ технологияләр институтында **«СКВАЖИНАЛАРНЫ ГЕОФИЗИК ТИКШЕРЕНҮДӘ ЗАМАНЧА МЕТОДЛАР»** дип исемләнгән курслар узды. Алар «ТНТ-Групп», ТГ АМИС, ТГ ЯМР, ОМП 31, «ТПГ-Казаньгеофизика» ҖЧҖ, «ТНГ-ЛенГИС» ҖЧҖ, «ТНГ-НурГИС» ҖЧҖ, «ТНГ-Ижгеофизсервис» ҖЧҖ, «ТНГ-АГИС» ҖЧҖ һ.б. оешма җитәкчеләре һәм белгечләре өчен махсус оештырылган иде.

• • • •

**3 СЕНТЯБРЬ** көнне «Казан ярминкәсе» күргәзмә комплексы базасында 21нче тапкыр **ТАТАРСТАН КАРА АЛТЫН-ГАЗ-ХИМИЯ ФОРУМЫ ЭШЛИ БАШЛАДЫ**. Форум кысаларында КФУ «Геодезия һәм геомәгълүмати системаларның актуаль мәсьәләләре» III Халыкара фәнни-гамәли конференция уздыра. Чарада шушы өлкәләр буенча 120ләп белгеч катнашачак.

• • • •

**4-7 СЕНТЯБРЬ** көннәрендә Мәскәү өлкәсендә урнашкан «Москва» автодромында беренче мәртәбә **«ФОРМУЛА СТУДЕНТ» ХАЛЫКАРА ЯРЫШЛАРЫНЫҢ РОССИЯ ЭТАБЫ ҮТӘЧӘК**. Студентларның инженерия юнәлешендә уздырыла торган әлеге масштаблы проект яшьләр мохитендә инженерлык белемен популярлаштыру һәм аларның иҗади потенциалын үстерү максатын күздә тота. Быел әлеге ярышларда КФУның Яр Чаллы институты автомобиль бүлегендә белем алучы студентлар узыш болидының 3D-проектын тәкъдим итәчәк.

• • • •

Быелгы уку елыннан **КАЗАН ХАЛЫКАРА ЛИНГВИСТИК ҮЗӘГЕНДӘ ПОЛЯК ТЕЛЕН ӨЙРӘНЕП БУЛАЧАК**. Телне өйрәнергә барлык теләүчеләр килә ала. Яшь, уку яисә эш, уку йорты буенча чикләүләр юк. Дәресләр атнага ике тапкыр кичке якта уздырылачак. Уку срогы 12 атна (барлыгы 72 сәгать). Тулырак мәгълүматны үзәкнең сайтында табарга мөмкин.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

## ● Белем көне

Ләйсән ИСХАКОВА

# Ышанычлы канат астында

**КФУда беренче курслар өчен бәйрәм тантанасы «Татнефть-Арена» Боз сараенда узды. Үзенең 210 еллык юбилеен каршылый торган уку йортыбызга быел барлыгы 9 меңнән артык абитуриент укырга кергән.**

Бу көнне студентлар адресына бик күп матур һәм ихлас теләкләр яңгырады. Ректорыбыз **И.Гафуров**, үз чыгышында, университет биргән зур мөмкинлекләр турында сөйләде. «Нәкъ менә бүгеннән сез, безнең хезмәттәшләребезгә әверелеп, КФУ коллективына килеп керәсез. Сезнең белем алырга гына түгел, ижат һәм спорт юнәлешендә дә сәләтләрегезне ачарга мөмкинлегегез булачак. Шуңа күрә алардан файдаланып калырга, илебезнең лаеклы кешеләре булырга ашкынығыз», – дип рухландырды ректор үз чыгышында.

Кайчандыр Казан университетының юридик факультетын тәмамлаган **Илсур Метшин** да беренчеләрне Белем көне белән тәбрикләп үз теләкләрен яңгыратты: «Мин сезне бу истәлекле көнегез белән котлыйм. Университетка башка авыл-шәһәрләрдән килгән студентларны аеруча билгеләп үтәсем килә. Казан сезнең туган шәһәрегезгә әверелсен иде!»

Чара бәйрәм концерты белән дәвам итте.

1 сентябрь КФУның IT-лицее укучылары өчен дә зур тантанага әверелде. Шул ук көнне ректор КФУның Н.И.Лобачевский исемендәге лицеенда белем алучы укучыларны да Белем бәйрәме белән тәбрикләде. Лицеистларга котлау сүзләрен Татарстан Дәүләт Советы рәисе **Ф.Мөхәммәтшин** да җиткерде. Тантаналы линейкада лицей директоры **Е.Скобельцына** уку йортының Татарстанның иң яхшы 10 урта белем бирү учреждениесе рәтенә керүен белдерде һәм укучыларны бу алдынгы урынны сакларга чакырды.

Әлбәттә, бу көнне Белем бәйрәмен университетның филиалларында дагерләтепуздырдылар. Мондый үзенчәлекле, истә калырлык чаралардан соң җиң сызганып укырга тотыну да куркыныч түгел инде!

## ●Халыкара бәйләнешләр

# Төрки дөнья берләшкән мәйдан

**Кичә КФУның Актлар залында тантаналы төстә Төрки дөньяның социаль фәннәре халыкара конгрессы ачылды.**



Влад Михневский фотосы

Быел 12нче тапкыр уздырыла торган әлеге чарага Төркия, Азәрбайҗан, Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Әфганстан, Иран һәм Россиянең төрле төбәкләреннән галимнәр, югары уку йортлары ректорлары, фән эшлеклеләре җыелды.

Конгресста катнашучыларны Татарстан Дәүләт Советы рәисе урынбасары **Р.Ратникова** сәламләде. «Безгә төрки кардәшләребезнең ничек яшәве хакында күбрәк белү, сезнең белән тәҗрибә уртаклашу мөһим. Казан берничә гасыр дәвамында төрки дөньяның алдынгы каласы булып саналды. Ул бу позициясен бүген дә югалтмый. Башкалада төрки халыклар арасында күренекле галимнәр яшәгән, иҗат иткән. Казан университеты – безнең горурлык. Быел 210 еллыгын бәйрәм итәчәк әлеге уку йорты бүген дә үсә, камилләшә. Конгресс төрле төрки илләрдән килгән фән вәкилләрен һәм галимнәрен берләштерер», – дип белдерде вице-спикер үз чыгышында.

КФУның Тышкы элемтәләр буенча проректоры **Л.Латыйпов** та үз фикерләрен җиткерде: «Быел Казан Түрксой оешмасы тарафыннан төрки дөньяның мәдәни башкаласы дип танылды. Шуңа конгрессның Казанда үткәрелүе очраклы түгел. Мондый чара бер-беребезне тыңлау, аңлау өчен генә түгел, ә танышу һәм дуслашу өчен дә киң мәйдан булып хезмәт итә».

Ачылу тантанасында Конгрессның координаторы профессор Әхмәт Вежди Джан да чыгыш ясады. Төркиядәге Гази университетының ректор киңәшчесе Эмин Куру да конгресска зур өметләр баглый. Ул төрки дөнья илләренә генә хас булган социаль проблемаларның бергәләп чишәргә чакырды.

КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү институты директоры **Р.Хәйретдинов** Казанда тюркологиянең барлыкка килүе һәм үсеш этаплары белән таныштырды. Нәкъ менә Казан университетында төрки халыкларны өйрәнү юнәлешендә зур эшләр башкарылган. Бу эшчәнлек бүген дә дәвам иттерелә. Конгресс кысаларында төрки дөнья илләренең тарихы, мәдәнияте, икътисады, сәясәтенә, Татарстан, Казан һәм КФУның төрки дөнья белән хезмәттәшлегенә бәйле мәсьәләләр турында фикер алышачаклар. Конгрессның эшчәнлеге секцияләргә бүлеп оештырылды. Бүген форум үз эшен тәмамлый.

## ● Гамәл һәм гадәт

# «Сез – безнең киләчәк»!

Алинә САДЫЙКОВА

**Сентябрьдә күпчелек студентларның яңа уку елы башланса, кайберләре өчен ул әле яңа тормыш башлану вакыты да. Сүзем беренче курс студентлары турында. Алар Казан федераль университеты дигән зур бер гаилә, бөтенләй башка мохит, үзгә дөньяга килеп керде. Шушы көннәрдә һәр институт һәм факультет яңа буынны каршы ала һәм үз «гаиләләре» белән таныштыра.**

ИТИС югары мәктәбендә бу процесс башка институтлардан аермалы һәм үзенчәлекле башкарылды: әлеге структур бүлекнең беренче курс студентлары үзләренең беренче уку көннәрен республикабызның IT паркында каршылады. Вакыйгаларның мондый борылыш алуының сәбәбе – студентларга тантаналы рәвештә республикабызның ИТ-индустриясеннән грант һәм студент билетларын тапшыру.



Матбугат үзәге фотосы

Бүгенге көндә дөньяда мәгълүмати технологияләрнең үсүе һәм зарури булуы беркем өчен дә яңалык түгел. Шуңа күрә республикабыз тарафыннан бирелгән әлеге грантларның актуальлеге, мөһимлеге һәр студент өчен зур мөмкинлекләр тудыруын һәркем анык аңлый. Татарстан республикасы хөкүмәте тарафыннан тәкъдим ителгән әлеге грант «Гамәли информатика» юнәлеше буенча белгечләр әзерләргә мөмкинлек бирә. Быел бу сан 350гә җитте. «Бу безнең өчен бик мөһим һәм әһәмиятле ярдәм! Безнең тырышлыкны күрәләр дигән сүз. Кабул итү сыйфаты да елдан-ел үсә. Быел кабул итү сыйфаты буенча Россия күләмендә беренче өчлеккә эләктек. Яндекс факультетының икътисад мәктәбе һәм Санкт-Петербург мәгълүмати технологияләр, механика һәм оптика милли тикшеренү университетлары белән бер рәттә торырлык дәрәҗәгә ирештек!» – дип уртаклашты үз фикерләре белән ИТИС югары мәктәбе директоры А.Хәсьянов.

Әйтергә кирәк, әлеге чара инде дүртенче ел рәттән үткәрелә. Ул – ТРның Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы һәм IT парк белән берлектә гамәлгә ашырыла торган проект. Шул рәвешле, республика инде 4 ел рәттән бу өлкәдә эшләячәк, аны үстерүдә һәм тагын да алга җибәрүдә лаеклы өлеш кертәчәк белгечләрне әзерләүдә ярдәм итә.

ИТИС югары мәктәбенең нигезендә әлеге грантлы уку моделе ята. Биредә төп басым лекция һәм теоретик әзерлеккә түгел, ә практикага бирелә, ягъни студентларны баштан ук эшләргә, мәсьәләнең асылына төшенергә өйрәтәләр. «IT-парк» Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк» директоры Антон Грачев фикеренчә, практика – белем алу процессында иң кирәкле компонент. Әлеге грантны иң яхшы студентлар гына ала. Беренче курслар аңа БДИ нәтиҗәләре буенча ия булалар. Аларның уртача баллары 78дән дә ким булмаска тиеш. Югары курсларга исә, ул уку нәтиҗәләре буенча бирелә.

Күренеп тора: шәкертләр җитди һәм төпле. Димәк, киләчәгебез дә шундый ук булачак!

• Сәяхәттән кайткач

Җәйге ялыбызның бер атнасын без, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегенең 4 курс студентлары, Әнҗе Хәнәфи кызы Кадыйрова һәм Халисә Хатыйп кызы Кузьмина җитәкчелегендә Мордовия Республикасында диалектологик практикада булып кайттык.

# Татарстан – Мордовия – Түбән Новгород

**Эльвина НӘҖИПОВА,**
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты



Практика дигәч, аны җиңел генә эш дип кабул итәргә ярамый. Безнең өскә бик зур җаваплылык йөкләнде. Саранск шәһәренең педагогия институты тулай торагына урнашып, һәр көн Ләмбрә районының Кырви һәм Сыркы авылы халкының гореф-гадәтләре, йолалары, аларның яшәү рәвеше белән таныштык сөйләм үзенчәлекләрен өйрәндек, диалекталь лексиканы барладык.

Күбебезнең әле бу беренче тапкыр зур сәфәргә чыгуы булды. Поездда барганда ук, һәрберебезгә эш йөкләнде. Без, тизрәктиешлеурынгабарып җитеп, максатларыбызны тормышка ашыру теләге белән яндык. Мордовиянең башкаласы Саранскида безне бик җылы каршы алдылар. Педагогия институты җитәкчеләренә, безгә практика дәвамында яшәргә уңайлы мөмкинлекләр тудырганнары өчен, рәхмәтебезне җиткерәбез. Беренче килгән көнебез төш вакытына туры килгәнгә күрә, көннең икенче яртысын Саранск шәһәре белән танышуга багышладык. Әнҗе Хәнәфиевна бу якларны бик яхшы белә икән, күңелле итеп эскурсия оештырды. Безне таң калдыргане Пушкин ял паркы булды. Ул үзе бер могҗизага тиң. Монда Пушкинның иҗатын тулысынча өйрәнеп чыгарга була. Һәр әкият герое үз урынында, песи дә чылбыр белән имәнгә бәйләп куелган. Шунда һәрберебез: «Менә безнең Казаныбызда Тукай паркы булсын иде», – дигән фикергә килде.

Икенче көнне иртәдән үк без үз эшебезгә тотындык: билгеләнгән авылларга киттек. Шунысы кызык: бер белмәгән, күрмәгән җирдә ничек каршы алырлар икән? Ләмбрә районы халкы бик кунакчыл, тәрбияле, ихтирамлы булулары белән күңелгә кереп калды. Безнең Казаннан килгәнебезне белгәч: «Татарлар, безнең туганнар», – дип, күз яшьләре белән каршы алдылар.

Авыллары да зур, чиста, матур. Шунысы күзгә ташланды: һәр йорт каршында таштан салынган уртача зурлыктагы йортлар бар. Алар элек-электән төрле әйберләр саклау бинасы ролен үтиләр икән.



Минем уйлавымча, безгә йөкләнгән эш тулысы белән үтәлде. Укып кына белгәннәребезне үз колакларыбыз белән ишеттек, үз күзләребез белән күрдек. Әбиләр безгә, яратып, «алтын алмам», «куяннарым», «оланнарым», «йөрәк маем», «макым» дип эндәштеләр. Алар безнең кебек өйдә түгел – «үдә», «ызба»ларда яшиләр. Бәрәңге түгел, «картук» ашыйлар, умарта түгел, ә «мурта» тоталар һәм тагын бик күп шундый үзенчәлекләр сакланган аларның сөйләмендә. Әбиапалар белән җырлашып, сөйләшеп утырганнар хәтерләрдә озак сакланыр әле.

Практиканың бер көнендә Болдинога да сәяхәт кылдык. Пушкин йөргән сукмаклардан атлап, ул яшәгән өй эчләрендә булып, илһамланып кайттык. Шагыйрь дә Болдинога илһам эзләп килә торган булган бит. Чыннан да, бу яклар безне гүзәл табигате, саф һавасы белән таң калдырды. Кызыклы практика оештырганнары, шундый гүзәллекләрне күрергә мөмкинлек биргәннәре өчен үзебезнең җитәкчеләргә мең рәхмәтлебез! Практикада тупланган материалларны барлап, һәрберебез дә Ләмбрә татарларының бай мирасы белән таныштырыр, булачак конференцияләрдә уңышлы чыгыш ясар, дигән өметтә калабыз.

• Табигать сагында

**Рөстәм ФӘРХУЛЛИН,** геогр.һәм экологик белем бирү теор.һәм метод.каф. асситетны


Июль аенда «Костер» сәламәтләндерү лагере базасында мәктәп укучыларының 20нче экологик-биологик җәйге профиль мәктәбе оештырылды. Чарада КФУ укытучылары да актив катнашты.



# Җәйге ял экологик лагерьда

Әйтергә кирәк, хәзерге көндә кайсы гына тармакны алсак та, экологик тәрбия юнәлешендәге эшчәнлек елдан-ел көчәя бара. Һәркайсыбыз өчен мөһим булган өлкә белән кызыксынучы яшьләрнең дә хәзер бу мәйданда үз идеяләре һәм карашлары бар. Мәктәпнең максатлары булып та нәкъ менә республикабызда талантлы һәм сәләтле яшьләрне барлау, экология, биология һәм география кебек фәннәрдән фәнни-тикшеренү эшләрен башкару мөмкинлекләрен ачыклау тора. Мәктәп ТР мәгариф һәм фән министрлыгы, әйдәп баручы югары уку йортлары белән берлектә уздырыла.

Мәктәптә республикабызның төрле районнарыннан экология, биология һәм география фәннәре буенча олимпиадада җиңү яулаган укучылар катнашты. Эш барышында алар экология фәненең төрле тармакларын якыннан өйрәнеп тәҗрибә туплады. Мәктәп эшчәнлегенең нәтиҗәсе буларак, биредә төрле конкурслар, слетлар һәм викториналар оештырылды. Ахырдан жюри иң югары балл җыючыларны билгеләде. Абсолют җиңүче дип бөтен фәннәрдән иң югары балл җыйган Казан шәһәре Совет районының 121нче номерлы лицей укучысы Ольга Тимирбаева танылды. Аңа һәм башка җиңүчеләргә ТР мәгариф һәм фән министрлыгы белән экологик-биологик методик үзәгенең махсус диплом-грамоталары, КФУ укытучыларыннан истәлекле бүләкләр тапшырылды.





# Биеклектә сыналу

Актив һәм яңалыкка омтылган студентлар бер урында гына утырып тора, җәй буе ял итеп кенә ята алмый. КФУның «Семь румбов» турклубы әгъзалары да шундыйлардан!

Җәйге каникулларның нәкъ кызган вакытында студентлар белән бергә без, укытучылары, Кавказга өйрәнү походына юл тоттык. Әлеге поход 1нче категория нормативларын үтәү һәм «Россия туристы» билгесен алу максатыннан оештырылды. Сәяхәтебезне РФдә Мәдәният елы һәм Бөек Ватан сугышының 70еллыгына багышладык.

Елларда студентларны җәлеп итү авыррак булыр дип уйласам да, ялгышканмын икән. Алар бик теләп ризалыштылар. 29 июльдә башланган сәяхәт 9 августта тәмамланды. Без Краснодар краеның Абинск станицасыннан Кабардинка авылына кадәр җәяүләп бардык.

Шушы 10 көн эчендә кайда гына булмадык, кемнәрне һәм нәрсәләрне генә күрмәдек! Көнебез иртәнге 7дә башланса, хәлдән таеп, палаткаларны корып, кичке ашау әзерләү вакытыбыз кояшның баюы белән тәңгәл килә иде.

Җирле төбәкнең тарихи һәм истәлекле урыннары бик күп. Шапсугск станицасындагы тарихи урыннар барысы да чиста һәм пөхтә, җирле халык аларны һәрдаим карап тора. Гомумән, биредәге һәр объект турында күп кызыклы мәгълүмат алдык. Юкка гына бу төбәкне сер һәм риваятьләр дөньясы дип йөртмиләр икән.

Икенче көнне тауга менү һәрберебезнең хәтерендә мәңге сакланачак. Бөеклек, биеклек, куркыныч матурлык, сафлык – боларга әле тагын әллә нинди хисләр килеп кушылды. Көне буена 20 км араны үтеп, хәлдән таеп, палатка корырга гына җыенган җирдән куып җибәрүләр, елга һәм тау буенда кунулар, аяктагы сөялләр, Кара диңгездә су коену, Абин, Жане елгалары – болар барысы да сәяхәтебезне онытылмаслык иткән әйберләр. Һәм, әлбәттә, моның кадәр тырышлык һәм үҗәтлектән соң, без барыбыз да «Россия туристы» билгесе белән бүләкләндек!

Ишетәсенме? Якын-тирәндәгеләр әллә ниди сүзләр белән сөйләшә?! Борчылма: бик тиздән син дә ул телне аңлый башларсың! Чөнки син хәзер СТУДЕНТ! Шуңа күрә синең игътибарыңа «Студент сүзлеге» тәкъдим итәбез. Бөлки әле югары курс студентларына да ярдәме тиеп куяр.

# а - я
# Студент сүзлеге



## А

**Alma Mater** ( лат. «туендыручы, игелекле ана» дигәнне аңлата) – рухи яктан туклandыручы (уку йортларының борынгы, формаль булмаган исеме).

**Автомат –** ул төрле булырга мөмкин. Яхшы укыганнарга имтиханны автомат рәвештә генә куялар, шулай ук аны кирза итек һәм каска белән бергә алырга да мөмкин.

**Академка** (академ ял) – университетта тагын бер ел артыграк уку мөмкинлеге.

**Аспирант –** югары белеме булган (еш кына андыйларны «ботаннар» дип йөртәләр), аспирантурада фән белән шөгыльләнүче кеше. Башлаган эшен ахырына кадәр җиткергән бу төркем кешеләргә кандидат дигән гыйльми дәрәҗә бирелә.

**Ашау –** студентларның иң яраткан әйбере. Ул аларга һәрвакыт кирәк! Еш кына аны игелекле күршеләрдән дә алып була. Аеруча егетләр күрше кызларында ашарга ярата.

## Б

**Бакалавр –** укыту программасын үзләштереп бетергәч бирелә торган дәрәҗә яки квалификация. Бу дәрәҗәгә ия кешеләр магистратура яисә аспирантурага кереп, белем ташын кимерүне дәвам итә ала.

**Бал –** шулай ук бик төрле булырга мөмкин: чыгарылыш, Вена; бездә исә син беренче курслар балына да эләгә аласың. Тагын «проходной балл» да бар. Син аны инде кичердең, шуны гына истә калдыр: бу сүздә ике «эль» языла. Мәктәптән аермалы буларак, вузда билгеләр урынына баллар куела.

**Белгеч –** уку йортын тәмамлап, таныклык алган кеше үзен шулай атый ала. Безнең илдә белгечләр 5 ел дәвамында әзерләнә.

**Билге –** зачеткадагы ыргаклар. Аларның 4 төре була:

**отл. –** укытучыны алдау;

**хор. –** укытучыны алдарга теләү, ләкин...

**уд. –** укытучы белән килешеп булды;

**неуд. –** укытучы белән килешеп булмады;

**Бомба –** экзамен сорауларына җавап әзерләү.Укытучың тотты исә, ул әкренәйтелгән тәэсирле бомбага әверелергә мөмкин.

## Д

**Диплом –** уку йортын тәмамлаганнан соң бирелә торган иң мөһим бүләк.

**Дуб –** беренче курс студенты.

## З

**Зачёт –** сессиягә кертелер өчен, укыган фәннәр буенча «зачёт» алырга кирәк. Семестр ахырында «зачёт атнасы» була, нәкъ менә шунда «зачёт» алу мөмкинлеге туа да инде.

**Зачётка –** бу китапчыкка имтихан һәм зачёттан кала, укытучыларның автографларын да җыярга кирәк булачак. Гәрчә син аларның фанатлары булмасаң да. Исеңдә калдыр: әлеге тылсымлы китапчыктан башка сиңа зачётка да, имтиханга да юл ябык.

## И

**Интернет –** һәр студентка кирәк булган әйбер. Анда кызыклы һәм шул ук вакытта файдалы ресурсларга юлыгып була. Мисал өчен, КФУ сайтына: http://kpfu.ru/

## К

**Конференция –** акыллы булып кыланырга менә дигән чара, әле аның өчен «зачёт» та алу мөмкинлегең бар.

**Койрык –** һич кенә дә борынгы ата-бабаларыбыздан калган атавизм билгесе түгел, ул һәр ради студентта булырга мөмкин. Койрык – билгеле бер предметлар буенча җыелган әҗәтләр. Без бит homo sapiens вәкилләре, шуңа койрыкка үсәргә ирек бирмәгез!

**Куратор –** төркемнең «түрәләре» староста белән генә чикләнми, аңардан өстенрәк куратор вазифасын башкаручы бар. Кыскасы, ул «икенче әни».

**Курсовик –** йокысыз үткәргән төннәр нәтиҗәсе. Алардан соң син дәфтәреңдә кыек-мыек язылган язуларны таный башлыйсың һәм шуның нәтиҗәсендә 20-30 бит тирәсендә текст барлыкка килә.

## Л

**Лаба –** лаборатор эш. Теорияне гамәлдә куллану. Шулай ук нурланыш алу һәм 220 Вны татып карау өчен дә менә дигән мөмкинлек.

## М

**Магистр –** әгәр 6 ел уңышлы гына укып чыксаң, сиңа шундый академик дәрәҗә биреләчәк. Магистратура – бакалавриаттан соң килә торган белем баскычы. Күп кенә илләрдә магистр дипломы иң яхшылардан санала. Шуңа күрә, әлеге биеклеккә ирешү өчен, беренче баскычка ук ышанычлы адымнар белән басарга кирәк.

## Н

**Неуд. –** иң начар билге. Әгәр сессия вакытында шундый ике билге алсаң, укудан вакытыннан алда азат ителергә әзерлән.

**Неявка –** «неуд»ка караганда яхшырак. Академкага китү мөмкинлеге.

**Нәтиҗә –** университетта укуга йомгак ясау.

## О

**Окно –** буш пара. Окно вакытында син йоклап, лекция күчереп ала яисә саф һавада йөреп керә аласың. Кыскасы, бу вакытны күңелең теләгәнчә үткәрергә мөмкин.

## П

**Пара –** студентның уку вакытын билгели торган берәмлек. Бу – 45 минутлык дәреснең икеләтелгән һәм 5 минутлык тәнәфесе булган формасы.

**Пересдача –** гадәттә, сессия вакытында һәм сессиядән соң була. Гомумән алганда, имтиханны бирә алмаганнан соң, аны бары тик 2 тапкыр гына яңадан бирeп карарга мөмкин. Ә менә өченчесе дәүләт комиссиясе катнашында уза һәм аның нәтиҗәсендә университеттан куылу куркынычы да юк түгел.

**Препод –** шул ук укытучы, әмма билгеләрне сирәгрәк куя.

## С

**Сессия –** «Студент сессиядән сессиягә кадәр күңелле яши!» Ә сессия вакытында тагын да күңеллерәк тормыш башлана. Сессия тиз генә дә үтеп китәргә мөмкин. Бигрәк тә «автоматлар» алсаң. Шул ук вакытта бу «күңелле» вакыт ай ярымга кадәр дә сузылырга мөмкин.

**Староста –** төркемнең әйдаманы. Ул студентлар өчен кирәкле һәм әһәмиятле булган мәгълүматларга ия кеше. Шуңа аның белән ызгышмаска киңәш ителә.

**Стипендия –** сессиясен уңышлы һәм вакытында тапшырган бюджетта укучы студент ай саен ала торган «хезмәт хакы».

**Студент –** бүген син горур рәвештә йөртә торган исем! Алай гына да түгел, син КФУ студенты!!! Аны лаеклы рәвештә аклау өчен, шактый тырышырга туры киләчәк. Юкка гына «укуэнә белән кое казу» димәгәннәр. Энәң юан саплы, коең бик тирән булсын!

**Студентлыкка багышлау –** сентябрьдә була торган бәйрәм. Анда студентлыкка багышлау йоласы үткәрелә. Әмма исеңдә калдыр: беренче сессияң ябылгач кына син чын студент булачаксың!

**Студент тормышы –** тормышның иң гүзәл вакыты. Бу чорда белем алып чыгарга да җөрьәт итәргә, ял итәргә дә, чын дуслар табарга һәм яхшы гына элемтәләр дә булдырырга кирәк.

## Т

**Төркем –** мәктәптә сыйныф дип аталып йөри торган әйбер университетта төркем дип атала.

**Тулай торак –** тудентларның икенче йорты. Биредә син яңа дуслар, лекцияләр, хәтта кайчакта ашау да таба алачаксың.

## Х

**Халява –** экзамен алды төнендә студентлар тулай торагы яныннан үткәндә, тәрәзәдән зачетка тоткан кулның сузылуын күрсәң һәм «Халява, кил!» дигән ялварулар ишетсәң, гаҗәпләнмә! Шул рәвешле студентлар имтихан уңышлы булсын дип тели.

## Ч

**Чыгарылыш –** университетта укуны тәмамлау.

## Ш

**Шпора –** лотерея билеты. Аның ярдәмендә син укуыңны дәвам итә алу бәхетенә ирешә аласың, әмма шул ук шпора аркасында университеттан «очып чыгу» куркынычы да юк түгел.

## Э

**Экзамен –** ике бик акыллы кешенең үзара сөйләшүе. Әмма әгәр аларның берсе бик үк акыллы булмаса, икенчесенең зачеттан колак кагуы бик ихтимал.

# Укытучы кулындагы стакан



Профессор дәресен башлар алдыннан кулына стакан алды. Анда бераз гына су бар иде. Укытучы стаканын барлык студентлар да күрерлек итеп күтәрде һәм соравын яңгыратты:

- Ничек уйлыйсыз, бу стаканның авырлыгы күпме?

- 50 грамм, 100 грамм, 125 грамм, – дип җавап бирде студентлар.

- Үлчәп карамыйча, аны мин дә белә алмаячакмын, – диде профессор. – Минем соравым шундый: әгәр мин аны хәзерге кебек берничә минут буе тотып торсам, ни булачак?

- Берни дә булмаячак.

- Ярар, ә әгәр мин аны бер сәгать буе тотып торсам?

- Сезнең кулыгыз оеячак, мускулларыгызның эшчәнлеге бозылачак һәм паралич булуы мөмкин. Сезгә хастәханәгә барырга туры килер иде...

- Бик әйбәт. Без әле бу темага сөйләшкән арада стаканның авырлыгы үзгәрдеме? – дип сорады профессор.

- Юк.

- Алайса кулны ни авырттыра һәм мускулларның эшчәнлеген нәрсә бозачак соң?

Студентлар аптырашта калды.

- Югарыда әйтелгәннәрне булдырмас өчен, миңа нәрсә эшләргә кирәк? – дип, профессор яңадан сорау бирде.

- Стаканны өстәлгә куегыз, – дип җавап кайтарды бер студент.

- Дөрес! – диде укытучы. – Тормыш проблемалары белән дә шулай. Алар турында берничә минут кына уйласаң да, бу уйлар шунда ук сине эзәрлекли башлый. Тагын да күбрәк уйлансаң, алар үзләрен ныграк сиздерә. Уйлауны һаман дәвам итсәң, проблемалар сине паралични һәм син моның белән берни дә эшли алмаячаксың.

Тормыш проблемалары турында уйлау бик мөһим, ләкин аларны тиешле урынына: көн азагына, икенче көнгә һәм башка вакыткарак алып куя белү күпкә мөһимрәк. Шул очракта син арымаячаксың, һәр таңны көчле һәм саф булып каршылаячаксың. Алай гына да түгел, синең янәшәңдә булган һәр проблема белән идарә итү мөмкинлегең туачак.

2014/15 уку елының 1 семестрына

## Дәресләр тәртибе

8.30 - 10.00
10.10 - 11.40
11.50 - 13.20
13.35 - 15.05
15.20 - 16.50
17.00 - 18.30
18.40 - 20.10
20.20 - 21.50.

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ЖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.